ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.12.2021 д. Канаш №28

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 29 ноябрендәге 1- номерлы һәм 2021 елның 30 ноябрендәге 2-1 номерлы, 2021 елның 1 декабрендәге 4-1 номерлы Канаш авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенында кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Канаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә гражданнарга үзара салым акчаларын җыю тәртибен раславга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Канаш авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Вальков

Канаш  авыл җирлеге Башкарма комитетының
2021 елның 2 декабрендәге 28нче номерлы
карарына

1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә
гражданнардан үзара салым җыю тәртибе

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге тәртип билгели

2. Үзара салым акчаларын түләү 2022 нче елның 1 нче гыйнварыннан 2022 нче елның 31 нче мартына кадәр Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, аларның халык җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, башкарыла.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

4. Түләүләр күләме гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен гражданнар җыены турында Карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:
а) 1 төркем инвалидлар
б) күпбалалы гаиләләр,
в) уку йортлары студентлары
г) Бөек Ватан сугышы ветераннары,
д) балачактан инвалидлар.

5. Бер тапкыр түләү турында белдерү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга почта элемтәсе аша имза астында тапшыру юлы белән җиткерелә.
Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

6. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына гражданнардан алынган үзара салым акчалары керә.

7. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешма аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (https://uslugi.tatarstan.ru) (сылтама буенча) почта күчерүләрен гамәлгә ашыруга хокуклы оешмалар аша башкарыла.

8. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Канаш  авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның 2
декабрендәге  28нче
номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районы Канаш  авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И. О.
________________________________________________________________________
Адресы: _________________________________________________________________
Сезгә ______________________________________нигезендә ___________________
вакытында кадәр _______________________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр _________________ сум түбәндәге реквизитлар буенча_________________________________________ түләргә кирәк.
Алучының  банк БИК _____________________________
Сч. № ______________________________
Алучының сч. №  ___________________________________
ИНН ___________________________________
КПП ___________________________________
КБК _______________ ОКАТО_____________
Түләү билгеләү
_____________________________________________________________________

Җитәкче _________________        ______________________________
(имза)                (имзаны роасшифровкалау)

М. у.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
_______________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
бюджетына үзара салым буенча ________________ суммада бер тапкыр түләү турында
Түләүченең Ф.И.О. ___________________________________
Адресы: _________________________________________________________________
Алган «__» _______________ 20__ ел___________________
( түләүченең имзасы)

Искәрмә. Аермалы кәгазь тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылса _______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала .